# СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ШИГЫРЬ ҺӘМ ПОЭМАЛАРЫНДА СУГЫШ ТЕМАСЫ

**Ләйсән Рәдиф кызы Надыршина,** *филология фәннәре кандидаты*

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Leysan_tatar@mail.ru

**Аннотация**

Мәкаләдә татар халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Сибгат Хәкимнең шигырь һәм поэмаларында сугыш темасының яктыртылышы анализлана. Шагыйрьнең сугыш темасына язылган әсәрләре, иң беренче чиратта, шәхси хатирәләр, кичерешләргә нигезләнә, чөнки С.Хәким – сугышта катнашкан шәхес. Аның фронт шигъриятендә туган якны сагыну, аерылу, киләчәккә бәйле өмет мотивлары төп урын алып тора. Бу мотивлар гади солдат кичерешләрен, психологик халәтен, күңел дөньясын ачып бирүгә буйсындырыла. Сугыш темасы шагыйрьнең 1950 еллардан соң иҗат ителгән шигырь һәм поэмаларында да зур урын алып тора. Бу әсәрләрдә яшьлеген сагынган лирик герой беренче планга куела, хәтер мотивы әйдәп баручылардан була. Сугыш темасына С.Хәким поэма жанрында иҗат ителгән әсәрләрендә дә иркен мөрәҗәгать итә. “Бакчачылар”, “Дуга” кебек поэмаларында сугыш фаҗигасе аерым шәхесләр язмышын сурәтләү аша ачып бирелә.

**Төп сүзләр:** Сибгат Хәким, татар әдәбияты, шигырь, поэма, тема, Бөек Ватан сугышы.

## THE THEME OF WAR IN SIBGAT HAKIM'S POETRY

**Abstract**

The article analyzes the coverage of the war in the poems and poems of Sibgat Hakim, a Tatar folk poet and winner of the G.Tukai State Prize. The poet's works on the subject of war are primarily based on personal memories and experiences, because S. Hakim is a person who took part in the war. In his front poetry, the motives of missing the homeland, parting, and the hope for the future play a central role. These motives are subordinated to the disclosure of ordinary soldier’s experiences, psychological state, and world of mood. The theme of war also occupies a prominent place in the poet's poems and poems created after the 1950s. In these

works, the lyrical hero who misses his youth comes to the fore, and the motive of memory comes from the leaders. S. Hakim freely addresses the theme of war in his works created in the genre of poetry. In his poems such as “The Gardeners” and “The Arc,” the tragedy of war is revealed through the depiction of the fate of individuals.

**Keywords:** Sibgat Hakim, Tatar literature, poetry, poetry, theme, Great Patriotic War.

**Кереш**

Узган гасыр урталарыннан башлап, әдәби мәйданда төп көчләрне тәшкил итеп, татар милли сүз сәнгатендә үз урынын тапкан, үзенә генә хас иҗат стилен булдырган шагыйрьләр бик күп: Хәсән Туфан, Гамил Афзал, соңрак Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин һ.б. Шушы йолдызлар янәшәсендә үзенең салмак, бер караганда гади, һәркемгә якын һәм таныш, әмма олы фикри куәтле шигърияте белән Сибгат Хәким иҗаты да аерым урын алып тора.



**Сибгат Хәкимнең шигырь һәм поэмаларында сугыш темасы**

Сибгат Хәким – Бөек Ватан сугышын башыннан ахырынача кичкән фронтовик шагыйрь, шуңа күрә аның шигъриятендә язмышының бу дәһшәтле һәм фаҗигале чоры чагылыш тапмый кала алмаган. Сугышның беренче елларында ук, чор сулышыннан аермалы буларак, аның иҗатында лирик аһәңнәр алгы планга чыга, авторның игътибары гади солдатның хис-кичерешләрен, сагыну-сагыш утында янган рухи халәтен, киләчәккә бәйле өмет-хыялларын сурәтләүгә юнәлтелә; шигырьләрнең төп геройлары – сугышның дәһшәтле тынлыгында туган яктан килгән хатны укып дулкынланган, якыннарны искә төшерүче моңлы җыр тыңлаган, төшләрендә туган якларын күреп юанган сугышчылар. Шагыйрьнең фронт иҗаты чор шигъриятендә киң таралган тема һәм мотивларга бай. Сугыш темасына иҗат ителгән «Хат», «Фронтовик» кебек шигырьләрдә чор әдәбиятын лейтмотив рәвешендә иңләп узган аерылышу мотивы беренче планга чыга, шуның белән бәйле сагышлы халәттә лирик геройның бердәнбер юанычы буларак киләчәккә өмет мотивы күрсәтелә:

Илдә яу йөргән чагында
Ир кеше түзәрмени?
Айрылу җиңел түгел дә,

Кыз өмет өзәрмени? [Хәким, 1986: 58]

Шагыйрь иҗатында сугыш – кешенең психологик кичерешләрен иң киеренке ноктасына җиткергән күренеш дип раслана, баш очыннан үлем шәүләсе китмәгән шушы дәвердә кеше бер-берсенә, якыннарына карата мөнәсәбәтләрен яңадан күздән кичерә, күңелдә бары якын итү, ярату хисләре генә кала, вак үпкәләр онытыла. Алдагы көннең ни китерәсен белмәгән көннәрдә, күрешү-кавышуга өмет сүрелгәндә, лирик кичерешләр бөтен тулылыгы белән калкып чыга, хисләрне әйтеп калырга ашкыну шигырьләрдә еш очраган мотивка әйләнә:

Эшелон юлга кузгала.  
– Яшәп тә моңа кадәр,  
Белмичә йөргән икәнмен  
Кадреңне, Мәһибәдәр.

Сагыну, юксыну – сугыш чор шигъриятенең иң киң чагылыш тапкан мотивларыннан берсе. С.Хәким шигырьләрендә дә туган җирен сагынган лирик герой үзәккә куела, ә туган җир образы ул туган авыл, ата-ана, сөйгән яр, балалар образларыннан оеша, шуларны юксынган солдат хисләре шигырьләрнең төп эчтәлеген хасил итә. Еш кына сагыну мотивы ретроспекция белән алшартлана һәм үткәндә калган тыныч тормыш турында хатирәләр белән кушыла, шул ук вакытта киләчәк турында самими хыяллар да шигырь эчтәлеген баета. С.Хәким иҗатында туган якны сагыну мотивы җыр-моң образы белән дә үрелеп бирелә, «Ржев чигендә», «Туган җир көе» кебек шигырьләр шуңа мисал булып тора ала. Аларда җыр образы туган ил тавышы, туган җир турындагы якты хатирәләр булып тәңгәлләшә:

Нечкәреп җиткән күңелне  
Моңлы көй телеп уза;  
Бу – туган илем көе бит,  
Кем болай җырда суза?

Тыңлыйлар кырда үләннәр,  
Башларын җиргә иеп.  
Окоплар буйлап йөри көй,  
Саумысыз, дуслар, диеп [Хәким, 1986: 76].

Сугыштан соңгы иҗатында да шагыйрь әлеге теманы киң яктырта, сугыш хакындагы хәтер мотивы аның шигырь-поэмаларында төп мотивлардан булуын дәвам итә: «Үзебез азат иткән шәһәрләргә...» (1976), «Фронттан бирле...» (1976), «Утыз елдан соң блиндажда...» (1976), «Ветеран» (1978), «Сугышның дәһшәте, көче» (1979) һ.б. Еш кына әсәрләрдә яшьлек елларының сугыш чорына туры килүе, иртә олыгаерга мәҗбүр булуы турында ачынып уйланган, яшьлеген юксынган лирик герой кичерешләре хис катламын хасил итә:

Шинеле төрелгән тыгыз,

Өстә кат-катлы дуга.

Мин – яшьлегемә, ул минем

Текәлгән картлыгыма [Хәким, 1986: 49].

Хәтер мотивы шагыйрьнең «Немец дәфтәреннән» дип аталган шигырьләр циклында да төп лейтмотив булып һәр шигырьне иңләп уза, аларда сугыштан соң ничә еллар үткәч Германия җиренә барып чыккан лирик герой уйлануларында үткән белән бүгенге очраша, хәтер мотивы аша үткәнгә юнәлдерелгән ретроспектив чигенешләр хәзерге яшәештә бетә барган намуслылык, тугрылык, каһарманлык, рухи омтылышны сагыну буларак укыла.

С. Хәкимнең сугыш беткәч тә языла башлаган һәм 1957 елда тәмамланган «Бакчачылар» поэмасының нигезенә, Н. Юзиев билгеләвенчә, сугыш афәте белән көрәш, бу көрәштә ныклык, җиңүгә ышаныч, дуслык кебек мотивлар салынган [Юзиев, 1971: 19]. Дөрестән дә, әлеге мотивлар әсәрнең төп эчтәлеген формалаштыра, һәм С. Хәким тылдагы аерым кешеләрнең язмышын ачып бирүне төп максаты итеп куя. Поэманың беренче бүлегендә үк Зәй буендагы агачка сөялеп уйга калган бакчасы Сәлим картны сурәтләп, шагыйрь«Сәлим абзый ник борчуга төшкән?» дигән сорауга җавап эзли. Сәлим карт питомникта килеш картайган үсентеләрне чыгарып ташлаганга хәсрәтләнә икән:

Бакчачылар ул алмагачларны,

Үз куллары белән чокырга –

Тирән, зур чокырга аудардылар.

Оят инде, оят авылдан:

Сугыш елларының һәр көненнән

Хезмәт белән йолкып алынган

Шатлыкларын аудардылар шунда [Хәким, 1986: 193].

Әлеге шигырь юлларыннан күренгәнчә, сугыш елларында олы авырлык, кыенлык белән үстергән үсентеләрне ташлау вакыйгасы, һичшиксез, символик мәгънә белән баетыла. Моны үз чорында Н.Юзиев та билгеләп үтә. Анынча, бакча – тынычлык символы, ә бакчаны яшәтү – җиңүгә ышаныч символы [Юзиев, 1971: 22].Әлеге фикерне тагын да төгәлләштерсәк һәм бакча образының татар әдәбиятындагы традицион мәгънәсен яңартсак, бу поэмада без аның матурлык, матурлыкка омылыш булуын аңларбыз. Үсентеләрне базга күму вакыйгасы исә сугышның кеше күңелендә шушы омтылышны юк итүен раслый. Поэмага килеп кергән елау мотивы Сәлим картның борчылу дәрәҗәсен күрсәтә:

Караңгы баз бөтен бакчаңны

Йотар төсле... Сәлим күзләреннән

Ике бөртек яшь анда тамды [Хәким, 1986: 193].

Димәк, карт, ахыр чиктә, сугышның җир йөзендәге матурлыкны юк итәргә мөмкинлеген уйлап ачына, хәсрәтләнә. Бакчаны яшен суккан көнне кызының сугышта һәлак булу хәбәрен алуы Сәлим картның хәсрәт дәрәҗәсен тагын да көчәйтә, табигать стихиясе карт бакчачының шәхси фаҗигасенә аваздаш яңгырый. Шушы кайгылы хәбәрдән соң аның бакчаны коткарып калуга тагын да үҗәтләнебрәк тотынуы идея катламында кызының үлеме өчен үч алу мотивы кебек төгәлләшә: Сәлим карт, әйтерсең, яшеәштәге матурлыкны юк итүгә юл куймыйча, кызының гомерен өзгән явызлардан үч алырга тели. Шул рәвешле, шагыйрь сугыш китергән ямьсезлекне матурлык белән генә җиңеп була дигән фикерне яңгырата, ягъни поэмада сугышка идея-эстетик бәя гуманистик рухта чагылыш таба. Бу яктан Сәлим картның гамәлләре халык омтылышлары белән тәңгәл килә һәм Сәлимне гомумиләштерелгән образ буларак караган Ә. Давыдов фикерендә [Давыдов, 1953: 125], һичшиксез, хаклык бар.

«Бакчачылар» әсәренең соңгы өлешендә гомуми яңгыраш үзгәрә, сугыш барышындагы кискен борылыш өмет, җиңүгә ышаныч мотивларын алгыпланга чыгара. Өмет исә, үз чиратында, кешеләр күңелендә матурлыкка омтылыш тудыра: Сәлим карт янына тирә-юньнән кешеләр агыла, аларның барысына да үсенте кирәк, димәк, матурлыкка сусау әле бетмәгән. Шагыйрь яшәү мәгънәсен дә шушы мотив белән бәйләп куя:

Бизә, матурла, сөендер:

Яшәүнең бар мәгънәсе [Хәким, 1986: 206].

Димәк, «Бакчачылар» поэмасында шагыйрь сугыш һәм тынычлык, матурлык һәм аның югалуы, өмет һәм өметсезлек кебек мәңгелек төшенчәләр турында фәлсәфи уйлануларга бирелә.

Сугыш темасы «Дуга» поэмасында да калка. С.Хәким үзе билгеләвенчә, бу әсәр – истәлек-биография, ул шагыйрьнең 1968 елда үзе яуларда катнашкан урыннарга сәяхәте белән бәйле иҗат ителә. «Башта проза белән язарга исәп бар иде, материал күп, зур. Бөтенесен дә әйтеп бетерәсе килә. Язарга утыргач, прозаны шигырь җиңде. Ә шигырь җентекләп язуны яратмый. Ни булса да, мин, хисләрем артыннан ияреп, шигъри әсәремә кереп киттем. Дугада узган җиде көн, чирек гасырдан соң шагыйрьнең Дугада җиде көн эчендә туган кичерешләре, солдат кичерешләре» [Хәким, 1986: 293-294], – дип яза С. Хәким үзе. Вакыйгаларга, кичерешләргә С. Хәким бүгенге заман күзлегеннән карый, дөнья, Ватан, халык язмышын тарихи яссылыкта, лиро-эпик яссылыкта күз алдына бастыра:

Траншеялар өстендә таш мәктәп
(Күзләремдә шатлык, яшь бүген),
Аскы катта минем буын, аның
Өске катларында яшь буын.

Кайный яшьлек, кайный тормыш, тормыш
Үз дигәнчә йөри эш итеп,
Сугышларның өсләренә таштан
Сарайларын сала үч итеп... [Хәким, 1986: 256]

дип уйлана ул.

Лирик герой образы поэмада ике вакытны тоташтыручы функциясен башкара: лирик герой берьюлы чынбарлыкта һәм Дуга сугышы көннәрендә яши, ягъни әсәрне хәтер мотивы бер төенгә туплый:

Язмышларны бер урынга җыеп,
Миңа хәзер бер җеп төйнәсе.
Үткәннәрем кабатлана төштә,
Гел газаплый Ржев тирәсе [Хәким, 1986: 300].

Дәверләрне кисештерү чирек гасыр элек булган сугыш фаҗигасенә хәзергедән торып күз салырга мөмкинлек бирә, мәңгелек кыйммәтләр, кешелек кануннары турында уйланулар алга чыга.

**Йомгак**

Гомумән, С.Хәкимнең шигырь-поэмаларында сугыш темасы зур урын били. Сугыш вакыйгаларын шәхси кичерешләр яссылыгында ачса да, шагыйрь реаль чынбарлыкны бөтен нечкәлекләре белән ачуны максат итеп куймый. Аның шигырь һәм поэмаларындагы дөнья сурәте сугыш кыры белән билгеләнми, ул дәһшәтле еллар фаҗигасен, яу манзараларын тасвирлаудан читкә китә. Шагыйрь каләме гади солдатның күңел дөньясын, рухаи халәтен, кеше психологиясен ачып бирүгә хезмәт итә. Әсәрләрдә сугыш темасын ачуга буйсындырылган лирик мотивлар да шушы максатка хезмәт итә.

**Чыганаклар**

1. Давыдов Ә. Безнең яңа танышларыбыз // Совет әдәбияты. – 1953. – №5. – Б. 125.

2. Хәким С. Сайланма әсәрләр: ике томда. – Казан: Татар. Кит. нәшр., 1986. – 2 т.: Шигырьләр, поэмалар. – 407 б.

3. Юзиев Н. Сугыштан соңгы татар совет поэзиясе. 1945–1955. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – Б. 19.